РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24 октября 2022 № 305

**Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы гражданнары гаиләләренә ярдәм итү чаралары исемлеген раслау турында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, 05.10.2022 рН-12-250 өлешчә мобилизацияләү мәсьәләләре белән бәйле гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты киңәшмәсенең 3 пунктын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20.10.2022 № 1122 карары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Әтнә муниципаль районы гражданнары гаиләләренә ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Әтнә муниципаль районы гражданнары гаиләләренә ярдәм итү чараларының беркетелә торган исемлеген расларга.
2. Әлеге карарны (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм (http://atnya.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарда каралган ярдәм чараларын бирү Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәт үтүе чорында гамәлгә ашырыла.
4. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкчесе А.Ф.Каюмов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә район башкарма комитеты
24 октябрь 2022 ел № 305 карарына

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Әтнә муниципаль районы гражданнары гаиләләренә ярдәм итү чаралары исемлеге

1. Мәдәни вакыйгаларга һәм чараларга бушлай бару (шул исәптән алдан бронь ясап түләүле концертлар).
2. «Ашыт» мәдәни-спорт комплексына («Спорт мәктәбе» МБУ) бушлай бару:
- эш графигы буенча «Дулкын» ябык йөзү бассейнында иректе йөзү;
- эш графигы буенча тренажер залына бару;
- эш графигы буенча модульле чаңгы базасында бушлай чаңгы прокаты).
3. Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә чираттан тыш хезмәт күрсәтү.
4. 60 һәм 55 яшькә җиткән гаилә әгъзаларын (ир-атлар һәм хатын-кызлар) санатор-курорт юлламалары белән беренче чиратта тәэмин итү.
5. 7 яшьтән алып 17 яшькә кадәрге балалы гаиләләрне ялны оештыруга юлламалар белән беренче чиратта тәэмин итү (Әтнә районы Башкарма комитетының «2022 елда Әтнә муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында»гы 24.11.2021 ел, № 482 карары нигезендә).
6. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Әтнә муниципаль районындагы «Изгелек» үзәге хезмәткәрләре мохтаҗ гаиләләргә психологик ярдәм һәм өйдә хезмәт күрсәтү.
7. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә төп гомуми һәм урта гомуми белем алучы мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләреннән балаларны бушлай кайнар ризык белән тәэмин итү.
8. Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләрен Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы балаларны (балаларны) караган өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган айлык түләүдән азат итү.
9. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә мәктәпкәчә, төп гомуми һәм урта гомуми белем алучы хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләреннән булган балаларга психолого-педагогик ярдәм итү.